ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» октябрь 2021 ел № 349

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2021 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында торак урын мәйданының исәпкә алу нормасы һәм торак урын мәйданын социаль наем шартнамәсе буенча бирү нормасы турында» Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 19 апрелендәге 107 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасының Әгерҗе шәһәрендә һәм Әгерҗе муниципаль районында торак урыннарның бер квадрат метры бәясенең «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган партнерлыкның эксперт-консультация советы тарафыннан үткәрелгән уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшеренүләр нәтиҗәләрен исәпкә алып («Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыкның «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2021 елның 25 гыйнварындагы 10 номерлы хаты), Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2021 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күрсәткечләрен кушымта нигезендә билгеләргә:

1.1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең максималь әһәмияте: 14608,72 сум;

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.2.1 ялгыз яшәүче кеше өчен – 469 566 сум;

1.2.2 ике кешелек гаилә өчен – 939 132 сум;

1.2.3 өч кешелек гаилә өчен – 1 408 698 сум;
1.2.4 дүрт кешелек гаилә өчен – 1 878 264 сум;
1.2.5 биш кешелек гаилә өчен – 2 347 830 сум
1.2.6 алты кешелек гаилә өчен – 2 817 396 сум;
1.2.7 җиде кешелек гаилә өчен – 3 286 962 сум
1.2.8 сигез кешелек гаилә өчен – 3 756 528 сум.

2. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә әлеге карарда күрсәтелгән максималь чик күрсәткечләрдән файдаланырга, гражданнарны аз керемлеләр дип таныганда һәм аларны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар исәбенә куйганда, торак шартларын яхшыртканда файдаланырга.

3. Әлеге карарның гамәли көче 2021 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
21.10.2021 № 349
карарына кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керемнең яисә ялгыз яшәүче гражданның максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2021 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү МЕТОДИКАСЫ**

1. Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү нормасы буенча торак урыннар сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече (алга таба - хисап күрсәткече) формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП x РС x РЦ,

кайда:

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе, Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмый.

Татарстан Республикасы Әгерҗе шәһәрендә һәм Әгерҗе муниципаль районында торак урыннарның бер квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыкның эксперт-консультация советы тарафыннан үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәләре нигезендә («Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыкның 2021 елның 25 гыйнварындагы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2021 номерлы хаты), Әгерҗе муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 2021 елга 26087 сум тәшкил итә.

а) ялгыз яшәүче кеше өчен:
СЖ = 26087 x 18 = 469566 сум

б) ике кешелек гаилә өчен:
СЖ = 26087 x 18*2 = 939132 сум

в) өч кешелек гаилә өчен:
СЖ = 26087x 18 x 3 = 1408698 сум

г) дүрт кешелек гаилә өчен:
СЖ = 26087x 18 x 4 = 1878264 сум

д) биш кешелек гаилә өчен:
СЖ = 26087 х 18 х 5 = 2347830 сум

е) алты кешелек гаилә өчен:
СЖ = 26087 х 18 х 6 = 2817396 сум

ж) җиде кешелек гаилә өчен:
СЖ = 26087 х 18 х 7 = 3286962 сум

з) сигез кешелек гаилә өчен:
СЖ = 26087 х 18 х 8 =3756528 сум

2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме СЖ исәпләү күрсәткеченә тигез итеп кабул ителә.

Граждан гаиләсенен һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме түбәндәгечә билгеләнә:

1) торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә - гаиләнен һәр әгъзасына туры килә торган, СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) - КП) / (0,25 х PC),

кайда:

ПД - Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ - хисап күрсәткече;

ПС - бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма), (коммерция кредит оешмаларының ачык чыганакларыннан мәгълүмат буенча) елына 12 %, ягни аена 12/12/100 = аена 0,01);

КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

PC - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте;

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен исәпләү**

Табл. № 1

| НП - торак урыны нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум.) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак урынының базар бәясе (сум) | ПС - Бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте | Кредит буенча түләүнең җыелма айлык кереме белән нисбәте | Керемнең максималь әһәмияте (сум) (кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | |
| | | | 26087 | 12/12/100= 0,01 | 180 | 0,7 | 0,25 | |
| 18 | 469566 | 1 | 26087 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,25 | 14608,72 |
| 36 | 939132 | 2 | 26087 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,50 | 14608,72 |
| 54 | 1408698 | 3 | 26087 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,75 | 14608,72 |
| 72 | 1878264 | 4 | 26087 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,00 | 14608,72 |
| 90 | 2347830 | 5 | 26087 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,25 | 14608,72 |
| 108 | 2817396 | 6 | 26087 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,50 | 14608,72 |
| 126 | 3286962 | 7 | 26087 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,75 | 14608,72 |
| 144 | 3756528 | 8 | 26087 | 0,01 | 180 | 0,7 | 2,00 | 14608,72 |

**Гражданның һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләмен исәпләү**

1. Ялгыз яшәүче кеше өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) - КП) / (0,25 х РС) = 0,7 х 469566х0,01 / (1 -1/1,01180) / (0,25 х 1) = 3286,96/0,9/0,25 = 14608,72

2. Ике кешелек гаилә өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) - КП) / (0,25 х РС) = 0,7 х 939132 х0,01 / (1 -1/1,01180) / (0,25 х 2) = 6573,92/0,9/0,5 = 14608,72

3. Өч һәм аннан күбрәк кешелек гаилә өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) - КП) / (0,25 х РС) = 0,7 х 1408698 х0,01 / (1 -1/1,01180) / (0,25 х 3) = 9860,88/0,9/0,75 = 9398,214/0,8332166/0,75 = 14608,72